Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Бәйрәкәтамак авыл җирлегенең Подгорный торак пунктында 2026 елда гражданнарга үзара салым кертү турында
**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

№6 13 ноябрь 2025 ел

2025 елның 20 мартындагы «Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында»гы 33-ФЗ санлы Федераль законның 45, 69 маддәләре, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 45-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсе, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Бәйрәкәтамак авыл җирлегенең Подгорный торак пунктында гражданнар җыены

КАРАР ИТТЕ:

"Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Бәйрәкәтамак авыл җирлегенең Подгорный торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, 1 төркем инвалидларыннан, махсус хәрби операциядә катнашучылардан, аларның тол калган тормыш иптәшләреннән, көндезге бүлектә укучы студентлардан, Россия Армиясе сафларында хәрби хезмәт узучылардан тыш, 2026 елда 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертергә.

2.Алынган акчаларны түбәндәге эшләргә юнәлтергә:

- Подгорный торак пунктында су белән тәэмин итү һәм канализация системаларын, су җыю башнясын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итә торган башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау (скважина янында киртәләр кору, төзелеш материаллары сатып алу, скважина насосы белән идарә итү щитын сатып алу һәм урнаштыру, эшләр өчен һәм шартнамә буенча хезмәт күрсәтүләр өчен түләү);

- Подгорный торак пунктында традицион күмү урыннарын ремонтлау, киртәләр кору, төзекләндерү (зират территориясен киртәләп алу, төзелеш материаллары сатып алу, эшләр һәм шартнамә буенча хезмәт күрсәтүләр өчен түләү);

- Подгорный торак пунктында торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (җирлек юлларын карап тоту, юлларны кардан чистарту, грейдерлау, ягулык-майлау материаллары, трактор өчен запас частьләр сатып алу, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен шартнамә буенча түләү);

- Подгорный торак пунктындагы торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү (төзелеш материаллары сатып алу, гомуми файдаланудагы территориядә үлән чабу, ягулык-майлау материаллары сатып алу, эшләр һәм шартнамә буенча хезмәт күрсәтүләр өчен түләү)?» – соравы чыгарыла.

3.Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында түбәндәге веб-адрес буенча халыкка җиткерергә: http://pravo.tatarstan.ru Ютазы муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында түбәндәге веб-адрес буенча: http://jutaza.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Бәйрәкәтамак авыл җирлеге территориясендә махсус мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы
Бәйрәкәтамак авыл җирлеге башлыгы З.М.Әгълиева